| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 июля 2018 г. № 4000

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы 138 нче карары белән расланган Россия Федерациясенең һава киңлегеннән файдалануның федераль кагыйдәләренең 49 пункты, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2012 елның 16 гыйнварындагы 6 нчы приказы белән расланган «Россия Федерациясенең һава киңлегеннән файдалануны планлаштыруны оештыру» федераль авиация кагыйдәләренең 40.5 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 24 июнендәге 3237 нче, 2016 елның 13 декабрендәге 6675 нче, 2017 елның 8 февралендәге 588 нче, 2017 елның 3 маендагы 2747 нче, 2017 елның 28 сентябрендәге 5805 нче карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә, түбәндәге эчтәлектәге 75 пункт белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

«75. Яр Чаллы шәһәре өстендә авиация эшләре, парашюттан сикерү, һава судноларының демонстрацион очышлары, пилотсыз очу аппаратларының очышлары, бәйләп куела торган аэростатларны күтәрү, шулай ук алар хакында белешмәләр аэронавигация мәгълүматлары документларында күрсәтелмәгән Яр Чаллы шәһәре чикләрендә урнашкан мәйданнарга төшү (очып китү) өчен рөхсәт бирү».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ